РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

Буа шәһәре

10.07.2026

№ 1-15

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлеше, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен кушымта итеп бирелгән карта-схема нигезендә Карлы авыл җирлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенә кертү юлы белән үзгәртү инициативасы белән чыгарга

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тиешле муниципаль берәмлекләрнең чикләрен тәкъдим ителә торган үзгәртү буенча фикер әйтергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарылырга тиеш: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлегенең рәсми сайтларында түбәндәге адрес буенча урнаштырылырга: http://buinsk.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

ТР Буа муниципаль районы Советының

____ елдан _ номерлы карарына кушымта

**Үзгәрешләрне исәпкә алып, муниципаль берәмлекләр чикләренең карта-схемасы**

